# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге Мөслим торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

27.11. 2023 ел                                                                 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023 елның 20 ноябренда 08 сәгать 30 минутта, 09 сәгать 00 минутта, 09 сәгать 30 минутта, 10 сәгать 00 минутта, 10 сәгать 30 минутта, 11 сәгать 00 минутта, 13 сәгать 00 минутта, 14 сәгать 00 минутта, 14 сәгать 30 минутта, 15 сәгать 00 минутта, 15 сәгать 20 минутта, 15 сәгать 30 минутта, 16 сәгать 00 минутта, 21 ноябренда 08 сәгать 30 минутта, 13 сәгать 00 минутта, 15 сәгать 00 минутта, 16 сәгать 00 минутта, 22 ноябренда 08 сәгать 00 минутта, 09 сәгать 30 минутта, 11 сәгать 30 минутта, 13 сәгать 00 минутта, 25 ноябренда 09 сәгать 00 минутта, 10 сәгать 00 минутта, 11 сәгать 00 минутта, 14 сәгать 00 минутта, 15 сәгать 00 минутта этаплап узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елга, Мөслим муниципаль районы Мөслим авылында 18 яшькә җиткән һәр теркәлгән кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм ветераннарына, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләрдә һәм башка локаль конфликтларда катнашучыларга, Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә инвалидларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым билгеләргә, ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт буенча хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук хатынын, балигъ булган балаларын, ә алар булмаганда әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1. **Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудырырга, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру:**

-скверлар һәм балалар мәйданчыкларында килешү нигезендә төзәтү эшләре.

2. **Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

-парк һәм скверларда, Ык буенда буяу эшләре (материаллар алу һәм килешү буенча хезмәткә түләү);

-урам утлары яктыртуга хезмәт күрсәтү өчен килешүгә түләү;

-суспензия алу һәм сулыкларны чистарту (материаллар алу һәм килешү буенча хезмәткә түләү).

**3.Җирләү урыннарын карап тоту:**

-Мөслим зиараты юлына гравий салу һәм тигезләү (килешү буенча хезмәткә түләү);

-каты коммуналь калдыкларны ташу эшчәнлегең оештыруга килешү нигезендә түләү.

**4.Җирлек торак пункты чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, юынтык суны чыгаруны оештыру:**

Скважина бораулау, СУПН кую, су торбалары үткәрү, задвижка кую (килешү нигезендә хезмәткә түләү).

**5. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге юл эшчәнлеге:**

Мөслим авылы эчендә юлларны язгы һәм җәйге нормативларга туры китерү (килешү нигезендә хезмәткә түләү);

Юлларга билгеләр төшерү (килешү нигезендә хезмәткә түләү);
Мөслим авылы эчендәге юлларны грейдерлау (килешү нигезендә түләү);
Мөслим авылы урамнарында юл билгеләре кую (килешү нигезендә хезмәткә түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 6356 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 3578, бу 56,3 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 3523 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 55 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең Мөслим торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авылында 18 яшькә җиткән һәр теркәлгән кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм ветераннарына, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләрдә һәм башка локаль конфликтларда катнашучыларга, Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә инвалидларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук хатынын, балигъ булган балаларын, ә алар булмаганда әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтергә:

**1.Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудырырга, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру:**

-скверлар һәм балалар мәйданчыкларында килешү нигезендә төзәтү эшләре.

**2.Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

-парк һәм скверларда, Ык буенда буяу эшләре (материаллар алу һәм килешү буенча хезмәткә түләү);
-урам утлары яктыртуга хезмәт күрсәтү өчен килешүгә түләү;
-суспензия алу һәм сулыкларны чистарту (материаллар алу һәм килешү буенча хезмәткә түләү).

**3.Җирләү урыннарын карап тоту:**

-Мөслим зиараты юлына гравий салу һәм тигезләү (килешү буенча хезмәткә түләү);
-каты коммуналь калдыкларны ташу эшчәнлеген оештыруга килешү нигезендә түләү.

**4.Җирлек торак пункты чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, юынтык суны чыгаруны оештыру:**

Скважина бораулау, СУПН кую, су торбалары үткәрү, задвижка кую (килешү нигезендә хезмәткә түләү).

**5. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге юл эшчәнлеге:**

Мөслим  авылы эчендә юлларны язгы һәм җәйге нормативларга туры китерү (килешү нигезендә хезмәткә түләү);

Юлларга билгеләр төшерү (килешү нигезендә хезмәткә түләү);

Мөслим авылы эчендәге юлларны грейдерлау (килешү нигезендә түләү);

Мөслим авылы урамнарында юл билгеләре кую (килешү нигезендә хезмәткә түләү).

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Мөслим авыл җирлеге башлыгы А.Р.Хужин